# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2013, 2 март) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 17 статьяда:

а) $6^1$ өлештә "иренең яисә хатынының һәм балигъ булмаган балаларының" сүзләрен" үз гаиләсе әгъзаларының" сүзләренә алмаштырырга;

б) 7 өлештә "Әлеге статьяда" сүзләреннән соң "һәм әлеге Законның $17^1$ статьясында" сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле $17^1$ статья өстәргә:

"$17^1$ статья. **Чыгымнар турында белешмәләр тапшыру**

1. Дәүләт хезмәтенең Россия Федерациясенең тиешле норматив хокукый акты белән билгеләнгән исемлегенә кертелгән вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәре федераль законда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый

актларында, Татарстан Республикасы Президентының алар нигезендә кабул ителгән указында билгеләнгән тәртиптә үз чыгымнары, шулай ук үз гаиләсе әгъзаларының чыгымнары турындагы белешмәләрне яллаучы вәкиленә тапшырырга тиеш.

2. Дәүләт хезмәткәренең һәм аның гаилә әгъзаларының чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3. Дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның чыгымнарын, шулай ук аларның хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарын тикшереп торуны гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт органы (дәүләт органы бүлекчәсе йә күрсәтелгән органның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты) Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә.

4. Дәүләт хезмәткәренең үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмау яисә тулысынча яки дөрес итеп тапшырмау йә үз гаиләсе әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмау яисә тулысынча яки дөрес итеп тапшырмау, әгәр мондый белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булса, дәүләт хезмәткәрен дәүләт хезмәтеннән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.".

**2 статья**

"Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында" 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $10^1$ статьяда:

а) исемендә "керемнәре," сүзеннән соң "чыгымнары," сүзен өстәргә;

б) 1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Депутат ел саен "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы

йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр, хисап финанс елыннан соң килә торган елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенә (алга таба әлеге статьяда – комиссия) тапшырыла.

2. Депутатның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр әлеге Законның 1 – 3 нче кушымталары нигезендәге белешмәләр формалары буенча тапшырыла.";

в) 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

"3) җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләрен, пайларын) сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча үзенең чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, әгәр алыш-биреш суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елда төп хезмәт (эш) урыны буенча гомуми кеременнән артса, һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.";

г) 4 пунктта "керемнәре," сүзеннән соң "чыгымнары," сүзен өстәргә;

д) 5 пунктта "керемнәре," сүзеннән соң "чыгымнары," сүзен өстәргә;

е) 6 пунктта "керемнәре," сүзеннән соң "чыгымнары," сүзен өстәргә;

2) $10^3$ статьяда:

а) исемендә "Керемнәре," сүзеннән соң "чыгымнары," сүзен өстәргә;

б) 1 пунктның 1 пунктчасында "керемнәре," сүзеннән соң "чыгымнары," сүзен өстәргә;

в) 2 пунктта "керемнәре," сүзеннән соң "чыгымнары," сүзен өстәргә;

г) 6 пунктның 4 пунктчасында "керемнәре," сүзеннән соң "чыгымнары," сүзен өстәргә;

д) 7 пунктның 3 пунктчасында "керемнәре," сүзеннән соң " чыгымнары," сүзен өстәргә;

е) 18 пунктта "Керемнәр," сүзеннән соң "чыгымнар," сүзен өстәргә;

ж) 20 пунктта "керемнәре," сүзеннән соң "чыгымнары," сүзен өстәргә;

з) $10^4$ статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"$10^4$ статья. **Депутатлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, акчаларны алу чыганаклары хакында тапшырыла торган белешмәләрне "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларының соравы буенча аларда бастырып чыгару өчен бирү тәртибе**";

б) 1 пунктта:

беренче абзацта "һәм бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла" сүзләрен "һәм массакүләм мәгълүмат чараларының соравы буенча аларда бастырып чыгару өчен тапшырыла" сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:
"4) җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләрен, пайларын) сатып алу буенча чыгымнар турында, әгәр алыш-биреш суммасы депутатның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елда төп хезмәт (эш) урыны буенча гомуми кеременнән артса, һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турындагы белешмәләр.";

в) 2 пунктта:

беренче абзацта "һәм бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла" сүзләрен "һәм массакүләм мәгълүмат чараларының соравы буенча аларда бастырып чыгару өчен тапшырыла" сүзләренә алмаштырырга, "Керемнәр," сүзеннән соң " чыгымнар," сүзен өстәргә;

1 пунктчада "керемнәр" сүзеннән соң ", чыгымнар" сүзен өстәргә;

г) 3 пунктта "Керемнәр," сүзеннән соң "чыгымнар," сүзен өстәргә, "керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр" сүзләрен "керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр" сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 пунктта "Керемнәр," сүзеннән соң "чыгымнар," сүзен өстәргә;

е) 6 пунктта "керемнәр," сүзеннән соң "чыгымнар," сүзен өстәргә;

4) түбәндәге эчтәлекле 3 нче кушымта өстәргә:

"3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының чыгымнары, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында БЕЛЕШМӘ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе рәисе

_______________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Мин, ____________________________________________________________
________________________________________________________________________,
(Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы)
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________,
(эш урыны һәм биләгән вазыйфасы)

________________________________________________________________________
____________________________________ адресы буенча яшәүче,
(яшәү урыны адресы)
20_____ елның 1 гыйнварыннан 20____ елның 31 декабренә кадәр хисап чоры ахырына (хисап датасына) җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләрен, пайларын) сатып алуга кагылышлы алыш-бирешләр буенча һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында үз чыгымнарым, шулай ук минем
________________________________________________________________________
(хатынымның (иремнең), балигъ булмаган кызымның, балигъ булмаган улымның)
________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы)

________________________________________________________________________
(төп эш яисә хезмәт урыны һәм били торган вазыйфасы; төп эш яисә хезмәт урыны булмаган очракта – шөгыльләренең төре)

чыгымнары турындагы белешмәләрне хәбәр итәм:

1 бүлек. Күчемсез мөлкәт белән алыш-бирешләр турында белешмәләр

| № т/с | Милеккә сатып алынган мөлкәтнең төре һәм исеме[1] | Милек төре[2] | Урнашкан урыны (адресы) | Алыш-биреш суммасы | Алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |

[1] Күчемсез мөлкәт объектының төре (җир кишәрлеге, торак йорт, фатир, дача, гараж, башкалар) күрсәтелә.

[2] Милек төре (индивидуаль, гомуми) күрсәтелә; уртак милек өчен милкенә мөлкәт сатып алынган бүтән затлар (фамилиясе, исеме, атасының исеме яисә атамасы) күрсәтелә; өлешле милек өчен белешмәләр тапшыручы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының (гаилә әгъзасының) сатып алынган өлеше күрсәтелә.

## 2 бүлек. Транспорт чаралары белән алыш-бирешләр турындагы белешмәләр

| № т/с | Милеккә сатып алынган транспорт чарасының төре һәм маркасы[3] | Милек төре[4] | Теркәлгән урыны | Алыш-биреш суммасы | Алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | | | | | |

[3] Транспорт чарасы төре (җиңел автомобиль, йөк автомобиле, авыл хуҗалыгы техникасы, су транспорты, һава транспорты, башкалар) күрсәтелә.

[4] Милек төре (индивидуаль, гомуми) күрсәтелә; уртак милек өчен милкенә мөлкәт сатып алынган бүтән затлар (фамилиясе, исеме, атасының исеме яисә атамасы) күрсәтелә; өлешле милек өчен белешмәләр тапшыручы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының (гаилә әгъзасының) сатып алынган өлеше күрсәтелә.

3 бүлек. Кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар) белән алыш-бирешләр турында белешмәләр:

| № т/с | Оешманың атамасы һәм оештыру-хокукый рәвеше[5] | Оешманың урнашкан урыны (адресы) | Устав капиталы[6] (рубльләрдә) | Сатып алынган катнашу өлеше | Алыш-биреш суммасы | Алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.

20___ елның "____" ____________

(Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты имзасы)

(белешмәне кабул итеп алган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм имзасы)

[5] Оешманың тулы яисә кыскартылган рәсми атамасы һәм аның оештыру-хокукый рәвеше (акционер җәмгыять, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять, ширкәт, житештерү кооперативы һәм башкалар) күрсәтелә.

[6] Устав капиталы хисап датасына оешманың гамәлгә кую документлары буенча күрсәтелә. Чит ил валютасындагы устав капиталлары өчен устав капиталы хисап датасына Россия Банкы курсы буенча рубльләрдә күрсәтелә.".

**3 статья**

"Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында" 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2011, № 10), түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

"4. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары һәм Хисап палатасы аудиторлары җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләрен, пайларын) сатып алуга кагылышлы алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары, әгәр алыш-биреш суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елдагы төп хезмәт (эш) урыны буенча гомуми керемнән артса, һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының алар нигезендә кабул ителә торган норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә тапшырырга тиеш.".

**4 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында" 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2013, 2 март) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлештә "үз керемнәре," сүзләреннән соң "чыгымнары," сүзен өстәргә, "керемнәре," сүзеннән соң "чыгымнары," сүзен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

"3. Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның (Татарстан Республикасы Президентыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларыннан тыш) чыгымнарын, шулай ук аларның хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарын тикшереп торуны гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт органы (дәүләт органы бүлекчәсе йә күрсәтелгән органның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты) Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә.".

**5 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында" 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш), № 12 (VI өлеш); 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 7 (II өлеш); 2011, № 5; Ватаным Татарстан, 2013, 2 март) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә "керемнәре," сүзеннән соң "чыгымнары," сүзен өстәргә;

2) беренче өлештә "ел саен" сүзләрен төшереп калдырырга, "тәртиптә" сүзеннән соң ", срокларда" сүзен өстәргә;

3) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ һәм $1^2$ өлешләр өстәргә:

"$1^1$. Муниципаль хезмәтнең тиешле исемлеккә кертелгән вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм рәвеш буенча тапшырырга тиеш.

$1^2$. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларында, әлеге Законда, Татарстан Республикасы Президентының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.";

4) 2 өлештә "Керемнәре," сүзеннән соң "чыгымнары," сүзен өстәргә;

5) 3 өлештә "керемнәре," сүзеннән соң "чыгымнары," сүзен өстәргә;

6) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрне фаш итүдә яисә әлеге белешмәләрне Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда файдалануда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка ия була.";

7) 5 өлештә "үз керемнәре," сүзләреннән соң "чыгымнары," сүзен өстәргә, "керемнәре, " сүзеннән соң "чыгымнары," сүзен өстәргә;

8) 6 өлештә ", күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт" сүзләрен "тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт" сүзләренә алмаштырырга;

9) түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:

"8. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затларның чыгымнарын, шулай ук аларның хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарын тикшереп торуны гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт органы (дәүләт органы бүлекчәсе йә күрсәтелгән органның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты) Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә.".

**6 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. "Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында" 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $10^1$, $10^3$ һәм $10^4$ статьялары нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) шушы Закон үз көченә кергән көннән соң билгеләнгән сайлауларда сайланган чакырылышлардагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына (Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими профессиональ нигездә эшләүче депутатлардан тыш) карата кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 29 марты
№ 24-ТРЗ